ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 гыйнвар 2024 ел № 325

Башкарма комитетның
аерым карарлары үз көчен
югалтуны тану турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2015 елның 9 декабрендә, 2015 елның 16 декабрендә «Челнинские известия» газетасының 90, 92 саннарында бастырып чыгарылган һәм 2015 елның 20 августында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Муниципаль милектәге җир участогын даими (сроксыз) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4352 номерлы Башкарма комитет карары;

2) 2016 елның 20 июлендә «Челнинские известия» газетасының 52 санында бастырып чыгарылган һәм 2016 елның 1 августында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Муниципаль милектәге җир участогын даими (сроксыз) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 22 июнендәге 3185 номерлы Башкарма комитет карары;

3) 2018 елның 19 сентябрендә «Челнинские известия» газетасының 67 санында бастырып чыгарылган һәм 2018 елның 17 августында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Муниципаль милектәге җир участогын даими (сроксыз) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 14 августындагы 4576 номерлы Башкарма комитет карары;

4) 2018 елның 30 ноябрендә «Челнинские известия» газетасының 87 санында бастырып чыгарылган һәм 2018 елның 16 ноябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Башкарма комитетның «Муниципаль милектәге җир участогын даими (сроксыз) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4352 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 12 ноябрендәге 6629 номерлы Башкарма комитет карары;

5) 2019 елның 27 мартында «Челнинские известия» газетасының 21 санында бастырып чыгарылган һәм 2019 елның 21 мартында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Муниципаль милектәге җир участогын даими (сроксыз) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 20 мартындагы 1376 номерлы Башкарма комитет карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

И.С. Зуев